# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными» и Закон Республики Татарстан «О регулировании отдельных вопросов в области обращения с животными в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 декабря 2025 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 13 января 2012 года № 9-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан в сфере организации проведения мероприятий по предупреждению и ликвидации болезней животных, их лечению, защите населения от болезней, общих для человека и животных, а также в области обращения с животными» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10; 2015, № 7 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2020, № 1 (часть I), № 57 (часть I); 2023, № 81 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 4 части 1 статьи 1 дополнить словами «, за исключением деятельности при введении режима экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан»;

2) в приложении:

а) в подпункте 6 пункта 6 слова «, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного» заменить словами «в случаях, предусмотренных

законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан»;

б) в пункте 9 слова «, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного» заменить словами «в случаях, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан»;

в) в абзаце девятом пункта 11 слова «, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного» заменить словами «в случаях, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан»;

г) в абзаце пятом пункта 16 слова «в связи с наличием тяжелого неизлечимого заболевания или неизлечимых последствий острой травмы, несовместимых с жизнью животного» заменить словами «в случаях, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан»;

д) в абзаце первом пункта 20 слова «, имеющих тяжелые неизлечимые заболевания или неизлечимые последствия острой травмы, несовместимые с жизнью животного» заменить словами «в случаях, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан».

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 27 декабря 2019 года № 120-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в области обращения с животными в Республике Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2020, № 4 (часть I), № 26 (часть I); 2021, № 93 (часть I); 2022, № 77 (часть I); 2023, № 86 (часть I); 2025, № 1 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 4:

а) часть 1 дополнить пунктами $6^1 – 6^3$ следующего содержания:

«$6^1$) установление критериев отнесения ситуации, сложившейся на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан, к экстраординарной в области обращения с животными без владельцев;

$6^2$) утверждение порядка введения режима экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан и перечня мероприятий, которые могут быть проведены для ее разрешения;

$6^3$) утверждение порядка организации деятельности пунктов временного содержания животных;»;

б) часть 2 дополнить пунктом $1^2$ следующего содержания:

«$1^2$) принятие решения о введении режима экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики

Татарстан или части территории Республики Татарстан и обеспечение проведения мероприятий, направленных на разрешение экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан;»;

2) дополнить статьей $5^1$ следующего содержания:

«Статья $5^1$. **Перечень мероприятий при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев на территории Республики Татарстан**

Мероприятия при осуществлении деятельности по обращению с животными без владельцев на территории Республики Татарстан включают в себя:

1) отлов животных без владельцев, в том числе их транспортировку и немедленную передачу в приюты для животных;

2) содержание животных без владельцев в приютах для животных в соответствии с частью 7 статьи 16 Федерального закона;

3) возврат потерявшихся животных их владельцам, а также поиск новых владельцев поступившим в приюты для животных животным без владельцев;

4) возврат животных без владельцев, не проявляющих немотивированной агрессивности, на прежние места их обитания после проведения мероприятий, указанных в пункте 2 части 1 статьи 18 Федерального закона, либо обращение с животными в соответствии с пунктом 5 части 1 статьи 18 Федерального закона;

5) размещение в приютах для животных и содержание в них животных без владельцев, которые не могут быть возвращены на прежние места их обитания, до момента передачи таких животных новым владельцам или наступления естественной смерти таких животных;

6) содержание животных без владельцев в пунктах временного содержания животных;

7) умерщвление животных без владельцев в случаях, установленных частями 1 и 2 статьи $5^2$ настоящего Закона;

8) иные мероприятия в соответствии с частями 7 и 8 статьи 18 Федерального закона.»;

3) дополнить статьей $5^2$ следующего содержания:

«Статья $5^2$. **Осуществление мероприятий по умерщвлению животных без владельцев**

1. Животных без владельцев, содержащихся в приютах для животных, умерщвлять запрещено, за исключением случаев необходимости прекращения непереносимых физических страданий нежизнеспособных животных при наличии достоверно установленных специалистом в области ветеринарии тяжелого неизлечимого заболевания животного или неизлечимых последствий острой травмы, несовместимых с жизнью животного.

2. Животных без владельцев, содержащихся в пунктах временного

содержания животных, умерщвлять запрещено, за исключением случаев:

1) необходимости прекращения непереносимых физических страданий нежизнеспособных животных при наличии достоверно установленных специалистом в области ветеринарии тяжелого неизлечимого заболевания животного или неизлечимых последствий острой травмы, несовместимых с жизнью животного;

2) обнаружения специалистом в области ветеринарии у животного факта наличия болезни, опасной для человека и (или) других животных, либо если животное является переносчиком этой болезни;

3) проявления немотивированной агрессивности животным;

4) проведения мероприятий, направленных на разрешение экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан;

5) нападения животного на человека.

3. Процедура умерщвления животных без владельцев должна производиться специалистом в области ветеринарии гуманными методами, гарантирующими быструю и безболезненную смерть.»;

4) дополнить статьей $5^3$ следующего содержания:

«Статья $5^3$. **Режим экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев**

1. В случае возникновения экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области обращения с животными, принимает решение о введении режима экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан.

2. В решении о введении режима экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан должны быть указаны территория, на которой вводится режим экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев, основания для введения режима экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев в соответствии с критериями, установленными Кабинетом Министров Республики Татарстан, перечень мероприятий, направленных на ее разрешение, а также срок его введения, который не может превышать трех месяцев.

3. В случае введения режима экстраординарной ситуации в области обращения с животными без владельцев на территории Республики Татарстан или части территории Республики Татарстан отлову подлежат все животные без владельцев, в том числе стерилизованные животные без владельцев, имеющие неснимаемые или несмываемые метки.».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
26 декабря 2025 года
№ 98-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «хуҗасыз йорт хайваннарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү эшчәнлегеннән тыш, хуҗасыз хайваннарга» сүзләренә алмаштырырга;

2) кушымтада:
а) 6 пунктның 6 пунктчасында «дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен

«Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта «дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) 11 пунктның тугызынчы абзацында «дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

г) 16 пунктның бишенче абзацында «дәвалап булмаслык авыр чиренә яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләренә бәйле рәвештә» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

д) 20 пунктның беренче абзацында «дәвалап булмаслык авыр чире яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 86 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^3$ пунктлар өстәргә:

«$6^1$) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә барлыкка килгән вазгыятьне хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять итеп карау критерийларын билгеләү;

$6^2$) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү тәртибен һәм аны хәл итү өчен үткәрергә мөмкин булган чаралар исемлеген раслау;

$6^3$) хайваннарны вакытлыча тоту пунктлары эшчәнлеген оештыру тәртибен раслау;»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $1^2$ пункт өстәргә:

«$1^2$) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү турында карар кабул итү һәм Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятьне хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүне тәэмин итү;»;

2) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ статья өстәргә:

«$5^1$ статья. **Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар исемлеге**

Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) хуҗасыз хайваннарны аулау, шул исәптән аларны транспортировкалау һәм кичектергесез рәвештә хайваннар приютларына тапшыру;

2) хуҗасыз хайваннарны Федераль законның 16 статьясындагы 7 өлеше нигезендә хайваннар приютларында тоту;

3) югалган хайваннарны хуҗаларына кире кайтару, шулай ук хайваннар приютларына китерелгән хуҗасыз хайваннарга яңа хуҗалар эзләү;

4) сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз хайваннарны Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны үткәргәннән соң элек яшәгән җирләренә кире кайтару йә Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә хайваннарга карата мөнәсәбәт күрсәтү;

5) элек яшәгән җирләренә кире кайтарыла алмый торган хуҗасыз хайваннарны, мондый хайваннарны яңа хуҗаларга тапшырганчы яисә мондый хайваннарның табигый үлеме җиткәнче, хайваннар приютларына урнаштыру һәм аларда тоту;

6) хуҗасыз хайваннарны хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында тоту;

7) хуҗасыз хайваннарны әлеге Законның $5^2$ статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән очракларда юк итү;

8) Федераль законның 18 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләре нигезендә башка чаралар.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $5^2$ статья өстәргә:

«$5^2$ статья. **Хуҗасыз хайваннарны юк итү чараларын гамәлгә ашыру**

1. Хайваннар приютларындагы хуҗасыз хайваннарны юк итү тыела, моңа, хайванда ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан дөрес билгеләнгән дәвалап булмаслык авыр чир яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләр булса, яшәүгә сәләтсез хайваннарның түзеп булмаслык физик интегүләрен туктату зарур булган очрак керми.

2. Хайваннарны вакытлыча тоту пунктларындагы хуҗасыз хайваннарны юк итү тыела, моңа түбәндәге очраклар керми:

1) хайванда ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан дөрес билгеләнгән дәвалап булмаслык авыр чир яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләр булса, яшәүгә сәләтсез хайваннарның түзеп булмаслык физик интегүләрен туктату зарур булганда;

2) ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан хайванның кеше һәм (яисә) башка хайваннар өчен куркыныч булган чире булу факты ачыкланганда йә хайван бу чирне таратучы булганда;

3) хайван сәбәпсез агрессивлык күрсәткәндә;

4) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятьне хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар үткәргәндә;

5) хайван кешегә һөҗүм иткәндә.

3. Хуҗасыз хайваннарны юк итү процедурасы ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан тиз һәм авыртусыз үлемне гарантияли торган гуманлы алымнар белән башкарылырга тиеш.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $5^3$ статья өстәргә:

«$5^3$ статья. **Хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимы**

1. Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять барлыкка килгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге вәкаләтле органы Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү турында карар кабул итә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү турындагы карарда хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимы кертелә торган территория, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән критерийлар нигезендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү нигезләре, аны хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеге, шулай ук өч айдан артык булмаган вакытка аны кертү срогы күрсәтелергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимы кертелгән очракта, барлык хуҗасыз хайваннар, шул исәптән алынмый яисә юылмый торган билгеләре булган стерилизацияләнгән хуҗасыз хайваннар, ауланырга тиеш.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                                                                    Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 98-ТРЗ